**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 4 март № 135

г. Казань

Өйдә яки медицина оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне оештыру өлешендә озак вакыт дәвамында дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) һәм дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасы мөнәсәбәтләрен регламентлаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль законны, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль законны тормышка ашыру максатларында, «Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешнең 13 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Өйдә яки медицина оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне оештыру өлешендә озак вакыт дәвамында дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) һәм дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасы мөнәсәбәтләрен регламентлаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалид балаларга өйдә тәрбия һәм белем бирү тәртибе һәм инвалидларның белем алу мөмкинлеген тәэмин итү буенча социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2008 ел, 16 июнь, 401 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\135.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 4 март, 135 нче
карары белән расланды

## Өйдә яки медицина оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне оештыру өлешендә озак вакыт дәвамында дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) һәм дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасы мөнәсәбәтләрен регламентлаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә өйдә яки медицина оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем алу хокукын тормышка ашыру максатларында эшләнде һәм моның белән бергә белем бирү процессында катнашучылар арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

1.2. Өйдә яки медицина оешмаларында белем бирүне оештырганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокук актлары, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирә торган белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмалары уставлары һәм локаль актлары белән җайга салына.

1.3. Өйдә яки медицина оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирә торган белем бирү программалары (алга таба – гомуми белем бирү программалары) буенча белем бирүне оештырганда мөнәсәбәтләрдә катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:

озак вакыт дәвамында дәвалануга мохтаҗ белем алучылар, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар, шулай ук сәламәтлекләренең торышы буенча вакытлыча яки даими рәвештә белем бирү оешмаларына йөри алмый торган инвалид балалар (алга таба – укучылар);

укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре);

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыра торган дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмалары (алга таба – белем бирү оешмалары);

медицина оешмалары.

1.4. Өйдә яки медицина оешмасында белем алуны оештыру өчен нигез булып ата-аналар (законы вәкилләр) медицина бәяләмәсендә күрсәтелгән чорга өйдә яки медицина оешмасында белем бирүне оештыру турында белем бирү оешмасы җитәкчесе исеменә язган гариза тора.

Өйдә белем алуга хокук бирә торган авырулар исемлеге федераль законнар нигезендә раслана.

1.5. Өйдә яки медицина оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне оештыру өлешендә белем бирү оешмасының дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бу белем бирү оешмасының дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен үтәвенә күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла.

## II. Өйдә белем бирүне оештыру

2.1. Өйдә белем бирүне укучының даими яшәү урынына якын урнашкан белем бирү оешмасы гамәлгә ашыра.

Өйдә индивидуаль белем бирүне оештыру белем бирү оешмасы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Инвалид баланы белем бирү оешмасына алу гражданнарны белем бирү оешмаларына кабул итү өчен гамәлдәге законнарда билгеләнгән гомуми тәртиптә башкарыла.

2.3. Өйдә белем бирү өчен сәгатьләрнең атналык нагрузкасы күләме Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының уку-укыту планнары, укучыларның психофизик мөмкинлекләрен һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, индивидуаль уку-укыту планы нигезендә билгеләнә.

Өйдә индивидуаль белем бирүче педагог хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү тарифлана торган педагогик нагрузкадан чыгып гамәлгә ашырыла.

2.4. Белем бирү оешмалары ата-аналар (законлы вәкилләр) ризалыгы белән өйдә белем һәм тәрбия бирү өчен түбәндәге шартларны тудыра:

белем бирү оешмасы китапханәсендә булган дәреслекләрне, уку-укыту, белешмә һәм башка әдәбиятны бушлай бирә;

педагог хезмәткәрләр арасындагы белгечләр белән тәэмин итә, гомуми белем бирү программаларын үзләштерү өчен кирәкле методик һәм консультатив ярдәм күрсәтә;

укучының арадаш аттестациясен үткәрүне гамәлгә ашыра, әзерлеген оештыра һәм дәүләт йомгаклау аттестациясендә катнашуын тәэмин итә;

дәүләт йомгаклау аттестациясен узганнарга тиешле белем турында дәүләт үрнәгендәге документны бирә.

2.5. Ата-аналар (законлы вәкилләр), укучының эш урынын оештыруны кертеп, өйдә белем бирүне оештыру өчен шартлар тудыра һәм язу-сызу өчен таләп ителә торган кирәк-яраклар белән тәэмин итә.

2.6. Педагоглар коллективының өйдә индивидуаль белем бирүне оештыру мөмкинлеге булмаса, белем бирү оешмасы бу белем бирү оешмасында эшләми торган педагог хезмәткәрләрне җәлеп итәргә хокуклы.

2.7. Өйдә белем һәм тәрбия бирүгә бәйле булган тиешле белем бирү программалары белән күздә тотылмаган өстәмә чыгымнар ата-аналар (законлы вәкилләр) акчасы исәбеннән тотыла.

2.8. Белем бирү оешмасы һәм озак вакыт дәвамында дәвалануга мохтаҗ укучыларның, шулай ук инвалид балаларның ана-аналары (законлы вәкилләре) арасындагы мөнәсәбәтләр шартнамә белән рәсмиләштерелә, белем бирү оешмасы уставы һәм локаль актлары белән регламентлаштырыла.

2.9. Өйдә белем бирүне оештыру шартнамәгә кушымта булып торучы индивидуаль уку-укыту планы буенча үткәрелә һәм белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә эшләнә.

2.10. Дәресләр вакыты укучылар һәм (яки) аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) белән килештерелә.

2.11. Өйдә белем бирүне гамәлгә ашыру белем бирү оешмасы боерыгы белән расланган дәресләр расписаниесе нигезендә башкарыла.

2.12. Өйдә белем бирү дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып гамәлгә ашырылырга мөмкин.

## III. Медицина оешмаларында белем бирүне оештыру

3.1. Медицина оешмаларында белем бирү гомуми белем бирү программалары буенча укучылар өчен гамәлгә ашырыла.

3.2. Медицина оешмаларында озак вакыт дәвамында дәвалануда булган укучыларга белем бирү медицина оешмасы һәм медицина оешмасы урнашкан урында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасы арасында төзелгән шартнамә нигезендә үткәрелә.

Медицина оешмасында озак вакыт дәвамында дәвалануда булган (тернәкләнү үтүче) укучыларга белем бирүне оештыру турындагы бертип шартнамә Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан раслана.

3.3. Белем бирү процессын медицина оешмасында озак вакыт дәвамында дәвалануда булган укучыларга белем бирүне оештыру турында шартнамә төзегән белем бирү оешмасында эшләүче педагог хезмәтләрләр гамәлгә ашыра.

3.4. Озак вакыт дәвамында дәвалануда булган укучыларга белем бирүне оештыру максатларыннан чыгып, медицина оешмасы белем бирү оешмасына дәресләр үткәрү өчен урыннар бирә.

3.5. Укучылар өчен белем бирү процессы гомуми белем бирүнең үзләштерелә торган программасын исәпкә алып оештырыла.

3.6. Белем алу дәресләре укучылар медицина оешмасына кергәннән соң иң киме 3 – 5 көн үткәч башлана.

3.7. Медицина оешмасына кергәннән соң укучының дәресләре башлану вакытын, баланың сәламәтлегe торышына карап, дәвалаучы табиб белән берлектә укучы кергән бүлек мөдире билгели, бу турыда авыру тарихына тиешле язу языла.

Дәресләр үткәрелә торган чорга укучыга сәламәтлегенең торышы буенча укырга ярамаган вакыт керми.

3.8. Медицина оешмасында озак вакыт дәвамында дәвалануда булган (тернәкләнү үтүче) укучыга белем бирүне оештыру өчен нигез булып медицина оешмасының бәяләмәсе һәм ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) медицина оешмасы җитәкчесе исеменә язма мөрәҗәгате тора.

3.9. Белем бирү процессы федераль дәүләт белем бирү стандартларына таянып эшләнә торган төп гомуми белем бирү программасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.10. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен белем бирү процессы бары тик ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) ризалыгы белән һәм психология-медицина-педагогика комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә адаптацияләнгән белем бирү программасы буенча, ә инвалидлар өчен инвалидны тернәкләндерүнең индивидуаль программасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.11. Белем бирү процессы белем бирү оешмасының педагоглар советында карала һәм кабул ителә, кул куйдыртып, ана-аналар (законлы вәкилләр), медицина оешмасының бүлек мөдире һәм дәвалаучы табибы белән килештерелә торган уку-укыту планы, уку-укыту графигы, дәресләр расписаниесе белән регламентлана һәм белем бирү оешмасының норматив акты белән раслана.

3.12. Белем бирү процессы укучыларның сәламәтлекләре торышын исәпкә алып оештырыла. Укучының көнлек уку нагрузкасы 3 – 3,5 академик сәгатьтән (балалар шифаханәләре өчен – 4 – 5 академик сәгать) артмаска тиеш.

3.13. Белем бирү процессы төркемдәге һәм индивидуаль дәресләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Белем алучылар саны бер кешедән алып өч кешегә кадәр булганда белем бирү индивидуаль уку-укыту планы буенча гамәлгә ашырыла.

Шулай ук индивидуаль дәресләр хәрәкәт итү мөмкинлегеннән мәхрүм булган укучылар һәм дәвалаучы табиб бәяләмәсе буенча ятып тору режимын үтәүче укучылар өчен үткәрелә.

3.14. Дәвалану чорында медицина оешмасында укучылар турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, тору урыны, укучы даими белем ала торган белем бирү оешмасы исеме), уку предметлары буенча дәресләр саны һәм эчтәлеге, гомуми белем бирү программаларын үзләштерүнең, арадаш аттестациянең шәхси нәтиҗәләре, сыйныфтан сыйныфка күчү, йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре һәм белем бирү оешмасын тәмамлап чыгу турында мәгълүматлар тиешле сыйныф журналында күрсәтелә.

3.15. Дәвалану чорында медицина оешмасында укучылар алар даими белем ала торган белем бирү оешмаларының статистика хисапларында исәпкә алына.

3.16. Укучылар үзләре файдалануындагы дәреслекләрдән һәм (яки) медицина оешмасында белем бирүне гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасы тарафыннан бирелә торган дәреслекләрдән файдалана.

Язу кирәк-яраклары белән укучыларны ата-аналар (законлы вәкилләр) тәэмин итә.

Интернат мәктәпләрнең һәм балалар йортларының ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы укучыларын, тәрбияләнүчеләрен язу кирәк-яраклары белән законлы вәкилләре тәэмин итә.

3.17. Укучыларга арадаш аттестация оештыру һәм үткәрү белем бирү оешмасының локаль норматив акты белән регламентлаштырыла.

3.18. Медицина оешмасыннан чыкканда укучыларга, укучыларның уку предметларын үзләштерү нәтиҗәләрен һәм белем алу вакытларын күрсәтеп, белешмә кәгазе бирелә.

Белешмә кәгазе белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм белем бирү оешмасы мөһере белән раслана.

3.19. Дәүләт йомгаклау аттестациясе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән затларга белем турында документлар бирелә.

3.20. Белем бирү оешмасы медицина оешмасында белем бирүне оештыру эшчәнлеген белем бирү оешмасының Россия Федерациясе законнары нигезендә эшләнгән локаль норматив акты нигезендә гамәлгә ашыра.

3.21. Укучыларның медицина оешмасында белем бирү программаларын үзләштерүен тикшерүдә тоту укучы даими белем ала торган белем бирү оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---